КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 23 май г.Казань № б-1059

Татарстан Республикасы бюджетының баланслылыгын тәэмин итү максатларында:

1. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

2026 – 2029 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын;

2026 – 2029 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын гамәлгә ашырудан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын киметү рәвешендә бюджет нәтиҗәлелегенә бәя бирүне.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле бюджетларның керемнәрен мобилизацияләүгә һәм чыгымнарын оптимальләштерүгә юнәлдерелгән муниципаль финансларны савыктыру чаралары планнарын кабул итүне тәкъдим итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 23 май, б-1059 нчы
боерыгы белән расланды

2026 – 2029 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планы

| Чараның исеме | Җаваплы башкаручылар | Башкару срогы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен арттыру чаралары | | |
| 1.1. Кирәк булганда, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән кайбер салым ташламаларын һәм түбәнәйтелгән салым ставкаларын гамәлдән чыгару турында карар кабул ителәә торган Татарстан Республикасының салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасының салым чыгымнары өчен җавап бирүче республика башкарма хакимият органнары | 2026 – 2029 еллар |
| 1.2. Оешмалар, шулай ук узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда салым түләүләрен киметкән оешмалар белән салымнар һәм җыемнар, аренда түләүләре буенча бурычларны (недоимканы) киметү буенча кирәкле эш башкару | | |
| 1.2.1. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым түләүләрен киметкән, шулай ук барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга түләүләр буенча бурычлары булган оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен үткәрү | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | квартал саен |
| 1.2.2. Татарстан Республикасы бюджетына оешмалар табышына салым буенча түләүләрне киметкән оешмаларга мониторинг үткәрү һәм | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республи- | квартал саен |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| республика башкарма хакимият органнары тарафыннан ведомство буйсынуындагы тармак предприятиеләре белән тиешле эшне оештыру | касы Икътисад министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), республика башкарма хакимият органнары | |
| 1.2.3. Оешмалар яктылыгында физик затлар керемнәренә салым керүләрне мониторинглау, муниципаль берәмлекләр яктылыгында узган елның шул ук чорына карата физик затлар керемнәренә салым керүне киметкән салым түләүчеләрне мониторинглау | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) | квартал саен |
| 1.2.4. Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына керә торган салымнар һәм җыемнар буенча муниципаль районнар һәм шәһәр округлары яктылыгында бурычларны мониторинглау һәм әлеге бурычларны кимтеүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) | ай саен |
| 1.2.5. Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча бурычларына ия оешмалар һәм физик затлар белән тиешле эш алып бару | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ай саен |
| 1.2.6. Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча үз вакытында түләнмәгән дебитор бурычларга мониторинг үткәрү, шулай ук шикаятьдәгъва эшенең сыйфатын яхшырту | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | квартал саен |
| 1.2.7. Республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, зур предприятиеләр хезмәткәрләренең мөлкәт салымнары буенча | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Федераль салым | 2026 – 2029 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| бурычларын каплау чараларын үткәрү | хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | |
| 1.3. Күләгәдәге мәшгульлекне легальләштерү һәм гражданнар керемнәренә салым салу буенча чаралар күрү | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча); | 2026 – 2029 еллар |
| 1.4. Акцияләре (устав капиталларындагы өлеше) Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре тарафыннан чиста табышларны бүлү һәм чиста табышларның кимендә 30 проценты күләмендә дивидендлар түләү практикасын дәвам итү | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 2026 – 2029 еллар |
| 1.5. Җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү белән бәйле чаралар үткәрү | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 – 2029 еллар |
| 1.6. Капиталь төзелеш объектларының дәүләт кадастр бәясен билгеләү бәйле чаралар үткәрү | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 – 2029 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2. Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү чаралары | | |
| 2.1. Тиешле финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсешен фаразлау буенча сценарий шартлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – ТР Финанс министрлыгы) | 2026 – 2029 еллар |
| 2.2. Инвестиция чыгымнарын оптимальләштерү | | |
| 2.2.1. Дәүләт (муниципаль) мөлкәтеннән нәтиҗәле файдалану максатларында төгәлләнмәгән төзелеш күләмнәрен киметү | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 – 2029 еллар |
| 2.2.2. Яңа инвестиция проектларын туктатып тору яисә соңрак вакытка күчерү турында карарлар кабул итү (кирәк булганда) | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 – 2029 еллар |
| 2.3. Бюджет челтәренең нәтиҗәлелеген арттыру һәм аны оптимальләштерү | | |
| 2.3.1. Нәтиҗәсез дәүләт (муниципаль) учреждениеләрен ачыклау, учреждениеләрне бетерү яисә үзгәртеп оештыру турында тәкъдимнәр әзерләү, шулай ук дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган оешмаларны дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтү процессына җәлеп итү мөмкинлеген карау (бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген исәпкә алып һәм оптимальләштерү максатларында) | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 – 2029 еллар |
| 2.3.2. Дәүләт хезмәтләре белән тәэмин итүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсенең үлчәнә торган күрсәткечләре системасын үстерүне кертеп, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне норматив буенча финанслау инструментларын куллану, билгеләнгән социаль гарантияләр дәрәҗәсенең фактта күрсәтелә торган хезмәтләр дәрәҗәсеннән тайпылышын бәяләү максаты белән дәүләт хезмәтләре белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсе аларның факттагы тәэмин ителешенә туры килү буенча регламент мониторингын гамәлгә ашыру һәм тәртибен камилләштерү, | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, республика башкарма хакимият органнары | 2026 – 2029 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| дәүләт эшләрен башкаруны норматив финанслау, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) билгеләнгән норматив чыгымнар кагыйдәләре буенча регламент нигезендә формалаштыру | | |
| 2.3.3. Бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр исәбеннән чыгымнар күләмен арттыру | республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының бюджет һәм автоном учреждениеләре | 2026 – 2029 еллар |
| 2.4. Гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтелгәндә аларны төгәлләштерү максатларында (кирәк булганда) адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларына анализ ясау | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 2026 – 2029 еллар |
| 2.5. Коммерциягә карамаган оешмаларга һәм юридик затларга аларның нәтиҗәлелеге предметына һәм бюджет чыгымнарын оптимальләштерү максатларында ярдәм чаралары күрсәтүне (субсидияләр бирүне) анализлау | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 – 2029 еллар |
| 2.6. Дәүләт һәм муниципаль сатып алуларны гамәлгә ашырганда заказчылар сатып ала торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр контрактының башлангыч (максималь) бәясенә үзәкләштерелгән анализ ясаудан файдалану | республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты | 2026 – 2029 еллар |
| 2.7. Дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштырганда хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары һәм күрсәткечләре системасын билгеләү, хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпкә алып, стимуллаштыру түләүләрен | республика башкарма хакимият органнары | 2026 – 2029 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| билгеләү | | |
| 3. Татарстан Республикасының бурыч сәясәтен камилләштерү чаралары | | |
| 3.1. Федераль норматив хокукый актлар нигезендә федераль бюджеттан бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының бурычын реструктуризацияләү / исәптән төшерү шартларын үтәү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 2026 – 2029 еллар |
| 3.2. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын минимальләштерүгә һәм (яисә) дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен чыгару һәм кредит оешмаларыннан кредитлар җәлеп итү юлы белән дәүләт бурычка акча алуны гамәлгә ашыруны күздә тотмый торган чыганаклар исәбеннән аны өстенлекле рәвештә финанслауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән алымнар кулланып, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 2026 – 2029 еллар |
| 3.3. Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирүне чикләү. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе белән йөкләмәләре тәэмин ителә торган принципалның финанс хәлен катгый контрольдә тотуны тәэмин итү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 2026 – 2029 еллар |

______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 23 май, б-1059 нчы
боерыгы белән расланды

2026 – 2029 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын гамәлгә ашырудан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын киметү рәвешендә бюджет нәтиҗәлелегенә бәя бирү

| Чаралар | Бюджет нәтиҗәлелегенә бәя бирү млн.сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел |
| 1. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен арттыру чаралары | 1 539,4 | 1 986,5 | 3 252,2 | 4 097,2 |
| 2. Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү чаралары | 5 352,7 | 6 485,7 | 6 055,3 | 10 982,3 |
| 3. Татарстан Республикасының бурыч сәясәтен камилләштерү чаралары | 29,0 | 13,6 | 54,4 | 60,0 |
| Барлыгы | 6 921,1 | 8 485,8 | 9 361,9 | 15 139,5 |

____________________